**Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Тыва Республикасы Хөкүмәте арасында икътисадый, мәдәни, социаль һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек турында килешү**

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов йөзендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте бер яктан һәм Тыва Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Тыва Республикасы Башлыгы Ховалыг Владислав Товарищтайович йөзендә Тыва Республикасы Хөкүмәте икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Тыва Республикасы законнарына (алга таба – законнар) таянып,

тигез хокуклылык һәм үзара файда принциплары нигезендә төбәкара багланышларны үстерү, Россия Федерациясендәге сәяси һәм икътисадый үзгәрешләрне исәпкә алып хезмәттәшлекнең хокукый нигезләрен ныгыту максатларында,

үзара файдалы хезмәттәшлекне киңәйтүнең Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы халкы мәнфәгатьләренә туры килүен, Татарстан Республикасының һәм Тыва Республикасының икътисадый үсешенә булышлык итүен танып,

ике яклы элемтәләрне тотрыклы һәм озак вакытлы нигездә үстерүгә үзара кызыксыну күрсәтеп һәм моның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка кирәкле шартлар булдырырга теләп, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

**1 статья**

Яклар хезмәттәшлекне үзара хөрмәт, тигез хокуклылык, партнерлык һәм икътисадый файда нигезендә үстерә.

Яклар үз вәкаләтләре чикләрендә үзара багланышларның һәръяклы үсеше өчен уңайлы шартлар булдыра.

Законнар нигезендә һәм бирелгән вәкаләтләр чикләрендә Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территорияләрендә теркәлгән һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баручы юридик затларның, шәхси эшкуарларның (алга таба – хуҗалык субъектлары) хезмәттәшлегенә ярдәм күрсәтә.

**2 статья**

Яклар бер-берсенә икътисадый яисә башка зыян китерерлек гамәлләрдән тыела, аларны кабул итү Якларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылырга мөмкин булган, кабул итү күздә тотылган карарларны килештерә һәм әлеге карарлар турында мәгълүмат алмаша.

## 3 статья

Яклар сәүдә-икътисадый һәм инвестиция хезмәттәшлеге өлкәсендә законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

хуҗалык субъектлары эшчәнлеге, шулай ук икътисадның үзара кызыксындыру тудырган тармакларына инвестицияләр кертү өчен уңайлы шартлар булдыра;

хуҗалык субъектлары арасында сәүдә-икътисадый, кооперация элемтәләрен үстерүгә булышлык күрсәтә;

производство-техник билгеләнештәге продукциянең әһәмиятле төрләрен, халык кулланышы һәм азык-төлек товарларын бер-берсенә китерүгә ярдәм итә;

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товар сатып алу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә хезмәттәшлек итә;

Татарстан Республикасының һәм Тыва Республикасының икътисадый мөмкинлекләрен үстерүгә юнәлтелгән уртак проектлар эшли, үзара кызыксыну тудырган тармакларда проектлар һәм белгечләр алмаша;

хуҗалык субъектлары арасында эшлекле багланышлар булдыру һәм аларны киңәйтү өчен шартлар тудыруга, Татарстан Республикасында һәм Тыва Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм ярдәм итү программаларын эшләүгә һәм тормышка ашыруга булышлык итә;

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә хезмәттәшлек итә, шул исәптән Татарстан Республикасының һәм Тыва Республикасының икътисадын үстерүне тәэмин итү һәм конкурентлык сәләтен арттыру максатларында инвестицион активлыкны стимуллаштыру чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра;

бизнес-миссияләрне, инвестиция мәйданчыклары һәм инвестиция мөмкинлекләре белән таныштыруны тәкъдим итүне оештыра, рәсми визитлар һәм эшлекле очрашулар кысаларында инвестиция проектларын тормышка ашыру буенча тәҗрибә алмаша, Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территорияләрендә инвестиция форумнары, конференцияләр һәм инновация эшчәнлегенең башка чаралары уздыру турында бер-берсенә хәбәр итә;

инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның аеруча нәтиҗәле рәвешләрен билгеләп, мәгълүмати-аналитик тәэминат системасын үстерә;

дәүләт-хосусый партнерлык механизмнарын үстерә;

инвестиция эшчәнлеге, инвестиция проектларын эшләүгә җитәкчелек итү һәм аларны гамәлгә ашыру өлкәсендә, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлык механизмнарын да файдаланып, хокуктан файдалану юнәлешендә иң яхшы тәҗрибәләр белән уртаклаша;

илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысаларында иң яхшы тәҗрибәләр, проектлар өлкәсендәге эшчәнлекне һәм ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру методикалары алмаша;

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны, шулай ук товар сатып алулары «Аерым юридик затлар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт

күрсәтүләрне сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына торган юридик затлар ихтыяҗларын тәэмин итү өчен etp.zakazrf.ru, 223etp.zakazrf.ru, sale.zakazrf.ru электрон мәйданчыкларын, bp.zakazrf.ru биржа мәйданчыгын файдалануга булышлык күрсәтә;

товарларга (эш һәм хезмәт күрсәтүгә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, бәя күтәрүне h.б.) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә, закон таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту, шулай ук гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә түләү күләме үзгәрүенең чик (максималь) индексларын билгеләү һәм аларның үтәлешен мониторинглау мәсьәләләре буенча тарифларны җайга салу органының җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлеген оештыру буенча хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша.

**4 статья**

Сәнәгать өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә тиешле оештыру шартлары булдыру юлы белән Яклар предприятиеләре һәм учреждениеләренә түбәндәге юнәлешләр буенча булышлык күрсәтә:

норматив хокукый актлар һәм программалар эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат алмаша;

шул исәптән агач эшкәртү, төзелеш материаллары җитештерү һәм башка өлкәләрне дә кертеп, сәнәгать проектларын гамәлгә ашыру буенча хезмәттәшлек итә;

геология өлкәсендә эзләнү эшләрен башкаруда хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша;

сәнәгать өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга федераль үзәк акчаларын файдалану өлкәсендә тәҗрибә алмаша.

**5 статья**

Авыл хуҗалыгы, дәүләт ветеринария күзәтчелеге һәм хайваннар дөньясының тотрыклы яшәеше өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә тиешле оештыру шартлары булдыру юлы белән Яклар предприятиеләре һәм учреждениеләренә түбәндәге юнәлешләр буенча булышлык күрсәтә:

үсемлекчелек, селекция, орлыкчылык, бөртекләләр һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын эшкәрткәндә, алдынгы технологияләрдән, үсемлекләр генофондыннан, үсемлекләрне саклауның экологик яктан чиста ысулларыннан һәм чараларыннан бергәләп файдалану;

терлекчелек, заманча технологияләргә нигезләнеп продукция бирүчәнлеге югары дәрәҗәдә булган авыл хуҗалыгы терлеген үрчетү, асрау һәм ашату, механикалаштырылган фермаларны техник яктан яңартуны тормышка ашыру;

биотехнология, авыл хуҗалыгы культуралары җитештерүгә һәм терлекләр үрчетүгә биотехнологик идарә;

эшкәртү һәм азык-төлек сәнәгате, җитештерү процессында механикалаштыру һәм автоматлаштыру чараларын комплекслы куллану.

**6 статья**

Сәламәтлек саклау өлкәсендә законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә Яклар казанышлар турында фәнни-гамәли мәгълүмат алмашуга, Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территорияләрендә халык сәламәтлеген саклау һәм күрсәтелә торган медицина хезмәтенең сыйфатын яхшырту өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү максатларында делегацияләр алмашуга булышлык күрсәтә.

**7 статья**

Халыкны социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

халыкны эш белән тәэмин итү, халыкка социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча, шул исәптән әлеге өлкәләрдә норматив хокукый документлар кабул итү һәм аларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча да, хезмәттәшлекне үстерә, социаль-икътисадый үсеш программаларын, гаиләгә, аналарга, балаларга, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга ярдәм күрсәтү социаль программаларын, хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау чараларын гамәлгә ашыру буенча үзара хезмәттәшлекне һәм тәҗрибә уртаклашуны тормышка ашыра;

яңа социаль технологияләр кертү өлкәсендә эш тәҗрибәсен өйрәнү өчен халыкны социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү органнары һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшен оештыру өлкәсендә иң яхшы тәҗрибәләрне алмаша;

эшсезлек һәм хезмәт базарындагы хәл, хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау өлкәсендә мәгълүмат-аналитика материаллары алмаша.

**8 статья**

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында һәм Тыва Республикасында уздырылган чаралар турында мәгълүмат алмаша;

аерым саклана торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, Кызыл китапларны алып бару, хайваннар дөньясы объектларын, су биоресурсларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә хезмәттәшлекне тәэмин итә;

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, калдыкларны сортларга бүлү, эшкәртү һәм аларны утильләштерүдә яңа технологияләрне гамәлгә кертү, табигатьне саклау структураларына идарәне камилләштерү мәсьәләләре буенча тәҗрибә алмаша.

**9 статья**

Мәдәният өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

аларда Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы коллективлары һәм башкаручылары катнашу мөмкинлеген булдыру максатларында булачак мәдәни вакыйгалар һәм чаралар, шул исәптән халыкара дәрәҗәдәге мәдәни вакыйгалар һәм чаралар турында мәгълүмат алмаша;

мәдәни багланышларны ныгытуга һәм үстерүгә булышлык итә;

иҗат коллективлары гастрольләрен оештыру һәм уздыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә, музей, сынлы сәнгать күргәзмәләрен алмашып үткәрә;

мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша.

**10 статья**

Мәгариф һәм фән өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

бергәләп конференцияләр уздыра;

уртак фәнни-тикшеренү проектларын тормышка ашыра;

заманча мәгариф технологияләре, мәгариф оешмалары эшчәнлеген җайга салучы норматив хокукый актлар проектларын эшләү буенча тәҗрибә алмаша.

**11 статья**

Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

мәгълүмат технологияләре өлкәсендә хезмәттәшлекне, шул исәптән төрле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру юлы белән дә, үстерә;

мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру буенча төбәктәге иң яхшы эшләр һәм тәҗрибәләр алмаша.

**12 статья**

Спорт һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы спортчылары һәм җыелма спорт командаларының Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территориясендә уздырыла торган спорт һәм массакүләм спорт чараларында катнашуына булышлык итә;

балаларның һәм яшьләрнең Татарстан Республикасында һәм Тыва Республикасында яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыруга юнәлтелгән чараларда катнашуына булышлык күрсәтә.

**13 статья**

Туристлык өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

туристлык өлкәсендә Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территорияләрендә уздырылачак чаралар турында мәгълүмат алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территорияләрендә эшчәнлек алып баручы туристлык оешмалары арасында үзара элемтәләр урнаштыруга булышлык итә.

**14 статья**

Төзелеш, архитектура, төзекләндерү һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

төзелешне оештыру, шәһәр төзелеше сәясәте, шәһәр җирендә уңайлы мохит булдыру һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә тәҗрибә алмаша;

төзелеш, архитектура, төзекләндерү һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә төбәк дәрәҗәсендәге иң яхшы эш тәҗрибәләре белән алмаша;

төзелеш, шәһәр төзелеше, архитектура темасына кагылышлы һәм шәһәр мохитен төзекләндерү мәсьәләләре буенча халыкара, төбәкара һәм республика күргәзмәләрендә, семинарларында һәм конференцияләрендә катнаша.

**15 статья**

Архив эше өлкәсендә Яклар законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә:

норматив һәм методик эшләнмәләр турында мәгълүмат һәм тәҗрибә алмаша;

архив хезмәткәрләре делегацияләре белән алмаша һәм архив учреждениеләрендә стажировка уза;

фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, архив документлары күргәзмәләре оештыруда һәм уздыруда һәм башка чараларда бергәләп катнаша;

тикшеренүләр алып бару, гражданнарның социаль-хокукый мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен кирәкле архив документларыннан һәм

фәнни-белешмә материаллардан файдалану мөмкинлеген булдыруга бер-берсенә булышлык итә.

**16 статья**

Әлеге Килешү аңа кул куйган Якларга финанс һәм (яки) мөлкәт йөкләмәләре салмый.

**17 статья**

Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру максатларында шартнамәләр (килешүләр), чаралар планнары төзергә, хезмәттәшлекнең тәгаен өлкәләрендә уртак чаралар уздырырга хокуклы.

Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен гамәлгә ашыруга булышлык итү һәм әлеге Килешү нигезендә Яклар тарафыннан кул куелган карарларның, беркетмәләрнең/чаралар планнарының үтәлешен контрольдә тоту максатларында Яклар икеъяклы сөйләшүләр уздыра һәм төбәкара ведомствоара эш төркемнәре төзи ала.

Әлеге Килешү Якларның өченче яклар белән төзелгән шартнамәләре (килешүләре) буенча йөкләмәләренә кагылмый һәм аларның кайсының да булса мәнфәгатьләренә каршы файдаланыла алмый яисә аларның өченче яклар алдындагы йөкләмәләрне үтәвенә киртә булмый.

Әлеге Килешүнең нигезләмәләре аерым хуҗалык субъектлары эшчәнлеге өчен башка хуҗалык субъектларының конкурентлыкка сәләтен чикләүгә һәм мәнфәгатьләрен кысуга китерәчәк уңай шартлар тудыру буларак карала алмый.

**18 статья**

Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру барышында килеп туган мәсьәләләрне тиз арада карап тикшерә һәм аларны законнар нигезендә уңай хәл итү өчен тиешле чаралар күрә.

**19 статья**

Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен аңлату һәм (яисә) куллану белән бәйле бәхәсләр туган очракта, Яклар аларны сөйләшүләр һәм консультацияләр уздыру юлы белән хәл итә.

**20 статья**

Әлеге Килешү аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм 5 (биш) елга төзелә, шул вакыт узганнан соң, Якларның берсе үзенең әлеге Килешүне өзәргә теләве хакында икенче Якка язма рәвештә белдермәсә, аннан алдагы 5 (биш) елга үзеннән-үзе озайтыла.

Әлеге Килешү Якларның берсенең икенче Якның әлеге Килешүнең гамәлен туктату нияте турында язмача хәбәрен алган көннән алты ай узгач, үз гамәлен туктата.

Яклар үзара килешеп әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертә ала, алар өстәмә килешүләр буларак рәсмиләштерелә һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

2022 елның «11» ноябрендә Казан шәһәрендә һәркайсы рус, татар һәм тыва телләрендә бер үк төрле юридик көчкә ия ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә башкарылды.

Әлеге Килешүнең рус, татар һәм тыва телендәге текстларында нинди дә булса төгәлсезлекләр яисә терминнарның мәгънә ягыннан эчтәлеге туры килмәү очраклары килеп чыкса, Яклар рус телендәге текстка таянып эш итә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хөкүмәте өчен | Тыва Республикасы Хөкүмәте өчен |
| Татарстан Республикасы Президенты | Тыва Республикасы Башлыгы |
| Р.Н. Миңнеханов | В.Т. Ховалыг |

12.11.2022
№ 56